| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13.06.2024 Баулы шәһәре №254

Баулы муниципаль район Советының
2021 елның 14 декабрендәге 93 номерлы
«Баулы муниципаль районы территориясендә
муниципаль торак контролен гамәлгә
ашыру турында» карарына үзгәрешләр
кертү турында

Баулы шәһәре прокуратурасының 2024 елның 15 февралендәге 02-08-02-2024 номерлы протестын карап чыгып, Баулы муниципаль район Советы **КАРАР ИТТЕ+**:

1. Баулы муниципаль район Советының 2021 елның 14 декабрендәге 93 номерлы «Баулы муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» карарына (2022 елның 11 апрелендәге 111 номерлы, 2023 елның 20 июнендәге 189 номерлы, 26.10.2023 елның 26 октябрендәге 224 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру кысаларында тикшерелә торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары исемлегендә 2 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат Рәсми порталында pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Баулы муниципаль районы рәсми сайтында bavly.tatar.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль район Советының икътисади үсеш, эшмәкәрлек, кече бизнес һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы Рәисе И.И. Гозәеров